СОВЕТ КУЗЕМБЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423710,Республика Татарстан,
Мензелинский район, с.Кузембетьево
ул.Мирная, 72

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХУЖЭМЭТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423710, Татарстан Республикасы,
Минзәлә районы, Хужэмэт авылы, Мирная ур.72

# КАРАР

## Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлеге составына кергән Хуҗәмәт торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**17 ноябрь 2019 ел.** **№ 4**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ нең 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы №45-ЗРТ Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 17 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар түбәндәге мәсьәлә буенча җыен беркетмәсе төзелде: “2020 елда Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлегенең Хуҗәмәт торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?”

1. Урам күрсәткечләрен ясату һәм урнаштыру ;

2. Совет урамы буенча парк территориясендә утырту өчен агачлар һәм куаклар сатып алу һәм утырту.

3.Совет урамы буенча парк территориясенә эскәмияләр сатып алу һәм утырту;
Совет урамы буенча парк территориясенә вазоннар сатып алу һәм урнаштыру;
Совет урамы буенча парк территориясендә юллар җәю өчен материал сатып алу һәм юллар җәю.

4. Сабантуй уздырыла торга урында күчмә эскәмияләр өчен материаллар сатып алу (эшләр өчен килешү буенча түләү);

5. Бәйрәмнәрне, “Сабантуй” милли бәйрәмен әзерләү һәм уздыру.

6. Приволье урамындагы рус зиратының коймасын өлешчә алыштыру.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 618 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар җыенында катнашучылар саны 329 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен 203 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;

"Юк" позициясе өчен 8 җыенда катнашучы тавыш бирде.

тавыш бирүдә тыелып калучылар – 118 катнашучы.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлегенең Хуҗәмәт торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – гамәлдә дип танырга.

2. "2020 елда Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлегенең Хуҗәмәт торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?" мәсьәләсе буенча карарны танырга:

1. Урам күрсәткечләрен ясату һәм урнаштыру ;

2. Совет урамы буенча парк территориясендә утырту өчен агачлар һәм куаклар сатып алу һәм утырту.

3.Совет урамы буенча парк территориясенә эскәмияләр сатып алу һәм утырту;
Совет урамы буенча парк территориясенә вазоннар сатып алу һәм урнаштыру;
Совет урамы буенча парк территориясендә юллар җәю өчен материал сатып алу һәм юллар җәю.

4. Сабантуй уздырыла торга урында күчмә эскәмияләр өчен материаллар сатып алу (эшләр өчен килешү буенча түләү);

5. Бәйрәмнәрне, "Сабантуй" милли бәйрәмен әзерләү һәм уздыру.

6. Приволье урамындагы рус зиратының коймасын өлешчә алыштыру.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Хуҗәмәт авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, Минзәлә муниципаль районы сайтында: http://menzelinsk.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы һәм http://pravo.tatarstan Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүматенең рәсми порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Гамәлдәге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлегенә җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче
муниципаль берәмлек Башлыгы — Вильданова Г.Г.

(имза) — (тулысынча имза)

Совет
КУЗЕМБЕТЬЕВСКОГО
сельского поселения
ИНН 1628002763